# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНДЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**дүртенче чакырылыш утыз дүртенче утырыш**

**29 июнь 2024 ел** **№ 103** **Баландыш ав.**

Баландыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 80 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Баландыш авыл җирлеге Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, рәис урынбасарлары, аудиторлары депутатларның хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Баландыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 80 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Баландыш авыл җирлеге Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә хакында» карарына (10.08.2018 ел №82; 09.10.2018 ел №93; 20.12.2018 ел №100; 08.05.2019 ел №112; 29.08.2019 ел №115; 24.10.2022 ел №64, 16.12.2022 ел №68) (алга таба текст буенча - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13323 сум итеп расларга.».

1.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Баландышавыл җирлеге Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи

затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең 6, 11.5 пунктларын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

1.2.1.«6. Баландыш авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләкләү билгеләнә. Айлык акчалата бүләкләү өчен чыгымнар күләме елына 12,86 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан артып китә алмый.».

1.2.2.«11.5 Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү билгеләнә.»

Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландышавыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 80 номерлы карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландышавыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата хезмәт хакы күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Айлык акчалата түләү, сум |
|---|---|
| | 12 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 18260 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 13324 |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Баландыш авыл җирлеге башлыгы: Р.Ш.Мөхәмәтшин